**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«11» 09 2024 ел № 3994

«ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе структурасына һәм штат санына үзгәрешләр кертү турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 мартындагы 979 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ составындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы 2 өлеше, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында» 2022 елның 29 мартындагы 583/22 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 02 августындагы 1381/24 номерлы боерыгы нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе структурасына һәм штат санына үзгәрешләр кертү турында» «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ составындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 мартындагы 979 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ мәгълүмат-методика бүлеге методисты (өлкәнне дә кертеп) компетенцияләре паспортын яңа редакциядә кушымта нигезендә расларга;

1.2. Педагогик мәгариф хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәдә:

2 бүлектә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ структурасындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айга база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр»,» «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясе бирелү белән раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 18405,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 18410,0 |
| | | | | |
| Структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләрнең мәгариф педагогик хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлеге мөдире (башлыгы) урынбасары;<br>Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләрнең мәгариф педагогик хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлеге мөдире (башлыгы); | - | - | 18481,0<br>18550,0 |

3.3 пункты 10 абзацка:

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклап калган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» билгесе, «Мактаулы остаз» билгесе» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен котрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның «18» 09 3994 номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ мәгълүмат-методика бүлеге методисты (өлкәнне дә кертеп) компетенцияләре паспорты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Методистның (өлкәнне дә кертеп) функциональ бурычлары җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеге, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 26 августындагы 761н номерлы боерыгы белән расланган «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары» бүлеге, «Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җитәкчеләр һәм методистлар эшчәнлеген бәяләүнең якынча критерийларын раслау турында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгының 2015 елның 10 августындагы под-8749/15 номерлы боерыгы (алга таба – 2015 елның 10 августындагы под-8749/15 номерлы боерык) нигезендә билгеләнә.

1.2. Квалификациягә таләпләр. Югары һөнәри белем һәм педагогик эшчәнлек стажы кимендә 2 ел. Өлкән методист өчен – югары һөнәри белем һәм методист вазыйфасында кимендә 2 ел эш стажы.

1.3. Методист мәгариф оешмаларының иң тәҗрибәле педагогик хезмәткәрләре арасыннан билгеләнә.

1.4. Методист гамәлдәге хезмәт законнарында билгеләнгән тәртиптә «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – «Мәгариф идарәсе» МКУ) башлыгы тарафыннан билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

1.5. Методист үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон, Россия Федерациясенең башка законнары, «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының башка законнары; Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Президенты Указлары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый, шул исәптән укучыларга белем бирү һәм тәрбияләү мәсьәләләре буенча актлары, хезмәтне саклау, куркынычсызлык техникасы һәм янгыннан саклану кагыйдәләре һәм нормалары, шулай ук «Мәгариф идарәсе» МКУ локаль норматив актлары, хезмәт шартнамәсе, күмәк шартнамәләр һәм башка норматив актларга таяна.

## II. Методистның (өлкәнне дә кертеп) һөнәри компетенцияләре

| Компетенция исеме | Компетенциянең характеристикасы | Компетенциянең эчтәлеге | | Әлеге компетенциянең башка компетенцияләр белән үзара бәйләнеше характеристикасы / әлеге компетенцияне формалаштыру өчен башка компетенцияләргә ия булу зарурлыгы | Бәяләү чаралары һәм технологияләре |
|---|---|---|---|---|---|
| Белем бирү сыйфаты белән идарә итү | Белем, осталык, идарә циклы элементларын куллана белү: максат кую, күрсәткечләр, мәгълүмат җыю һәм эшкәртү ысулларын сайлау, күрсәткечләргә мониторинг, мониторинг нәтиҗәләрен анализлау, анализ нәтиҗәләре буенча адреслы тәкъдимнәр эшләү, чараларны билгеләү һәм оештыру, идарә карарлары кабул итү, кабул ителгән чараларның нәтиҗәлелеген анализлау | 1. Белем бирү нәтиҗәләренең сыйфаты белән идарә итү | 1.1. Укучыларның әзерлек сыйфатын бәяләү.<br>1.2. Укыту нәтиҗәләре түбән булган һәм/яки уңайсыз социаль шартларда эшләүче мәктәпләр белән эшләү.<br>1.3. Балалар һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү.<br>1.4. Укучыларның үзбилгеләнүе һәм һөнәри юнәлеше буенча эш. | Методологик<br>Контроль-бәяләү<br>Технологик<br>Коммуникатив<br>Цифрлы грамоталылык компетенцияләре<br>Креатив фикерләү компетенцияләре<br>Тәнкыйди фикерләү компетенцияләре | Кадрлар аудиты (планлаштырылган күрсәткечләргә ирешүне бәяләү), тестлар, кейс-тестлар, сценарий тибындагы биремнәр |
| | | 2. Белем бирү эшчәнлеге сыйфаты белән идарә итү | 2.1. Мәгариф оешмалары җитәкчеләренең нәтиҗәлелегенә мониторинг.<br>2.2. Педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсешен тәэмин итү.<br>2.3. Укучыларны тәрбияләүне һәм социализацияләүне оештыру.<br>2.4. Мәктәпкәчә белем бирү сыйфатына мониторинг. | | |

## III. Методистның (өлкәнне дә кертеп) бурычлары

3.1. Өстенлекле милли бурычлар нигезендә һәм белем бирүнең сыйфатын күтәрүне тәэмин итү буенча педагоглар белән тотрыклы, системалы, адреслы оештыру-методик эш, барыннан да элек:

гомуми белем сыйфаты буенча Россия мәгарифенең глобаль конкурентлык сәләтен тәэмин итү;

белем бирү сыйфатын бәяләү системасын тәэмин итү;

яңартылган башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартларнын һәм федераль төп гомуми белем бирү программасын кертүгә булышлык итү;

укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыру һәм үстерү буенча педагогларга ярдәм итү;

массакүләм мәктәп белеменең сыйфатын күтәрү, белем бирүнең сыйфаты түбән булган мәктәпләрнең нәтиҗәләрен тигезләү.

3.2. Кураторлык иткән юнәлеш буенча ачыкланган педагогик хезмәткәрләргә һөнәри дефицит буенча эшне оештыру.

3.3. Кураторлык иткән юнәлеш буенча педагогик хезмәткәрләрне һәм идарәче кадрларны һөнәри үстерү процессына, белем бирү сыйфатын халыкара тикшеренүләрдә Россия укучыларының катнашу нәтиҗәләрен яхшырту бурычларын исәпкә алып, компетенцияләр формалаштыру программаларын кертү.

3.4. Кураторлык иткән юнәлеш буенча педагогик хезмәткәрләрнең предмет һәм метапредмет компетенцияләрен камилләштерү, шул исәптән «Хезмәт (Технология)» һәм «Ватан иминлеге һәм саклау нигезләре» дигән ике яңа предмет буенча.

3.5. Кураторлык иткән юнәлеш буенча педагогик хезмәткәрләрнең һәм идарәче кадрларның һөнәри осталыгын өзлексез үстерү шәхси маршрутларын төзү.

3.6. Педагогларны эксперт эшчәнлегенә җәлеп итү, кураторлык иткән юнәлеш буенча педагогларның үзара хезмәттәшлеген, үзара ярдәмләшүен һәм үзара белем алуын оештыру.

3.7. Яшь педагогларга ярдәм итү / кураторлык иткән юнәлеш буенча остазлык программаларын гамәлгә ашыру.

3.8. Педагогларның (методик берләшмәләрнең, педагогларның һөнәри бергәлекләренең) һәм мәгариф оешмалары җитәкчеләренең кураторлык иткән юнәлеш буенча үзара челтәрле хезмәттәшлеген оештыру.

3.9. Кураторлык иткән юнәлеш буенча педагогларның методик берләшмәләре һәм/яки һөнәри бергәлекләре эшчәнлеге торышын һәм нәтиҗәләрен анализлау.

3.10. Белем алу нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләргә һәм/яки уңайсыз социаль шартларда эшләүче мәктәпләргә кураторлык иткән юнәлеш буенча методик ярдәм күрсәтү.

3.11. Кураторлык иткән юнәлеш буенча укучыларның һөнәри үзбилгеләнү мәсьәләләре буенча педагогик хезмәткәрләргә ярдәм итү.

3.12. Тәрбия эше, шул исәптән укучыларга патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү, белем бирү киңлегенең психологик иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча педагогик хезмәткәрләрә булышлык итү (кураторлык иткән юнәлеш буенча).

3.13. ФООП, укыту-методик һәм программа-методик эшләнмәләр нигезендә эшче программалар төзегәндә, календарь-тематик планлаштырганда, укытучылар соравы буенча кураторлык иткән предмет өлкәләре буенча таләпләргә туры килү-килмәү предметына методик ярдәм күрсәтү.

3.14. Тәҗрибә алмашу һәм педагогларны методик камилләштерү максатларында фәнни-гамәли конференцияләр, практик семинарлар, педагогик укулар, һөнәри осталык конкурслары оештыру.

3.15. Кураторлык иткән предмет өлкәләре буенча район методик берләшмәләре эшчәнлеген координацияләү.

3.16. Үз квалификацияңне системалы күтәрү, һөнәри осталыкны камилләштерү.

3.17. Методик совет эшчәнлегендә, методик эшнең башка формаларында катнашу.

3.18. Районның мәгариф оешмаларында мәгариф өлкәсендәге максатчан программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруны методик тәэмин итүне һәм мониторинглауны оештыру.

3.19. Инновацион педагогик тәҗрибәне ачыклау, өйрәнү, гомумиләштерү.

3.20. Өстәмә һөнәри (педагогик) белем бирү учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру һәм методик эшне координацияләү.

3.21. Мәгариф оешмаларын кирәкле дәреслекләр һәм укыту-методик әдәбият белән тәэмин итү буенча системалы эш оештыру.

## IV. Методист (өлкәнне дә кертеп) белергә тиеш

4.1. Төп документларны:

Россия Федерациясе Конституциясе,

Татарстан Республикасы Конституциясе,

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы,

Россия Федерациясе Гражданнар кодексы,

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы,

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 № 273-ФЗ Федераль закон,

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 декабрендәге 1642 номерлы карары,

«Мәгариф турында» 22.07.2013 ел, № 68-ТРЗ Татарстан Республикасы законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 22.02.2014 ел, № 110 карары;

«2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы;

«Россия Федерациясе педагогик хезмәткәрләре һөнәри үсеше милли системасының, укытучылар үсеше милли системасын да кертеп, төп принципларын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 декабрендәге 3273-р номерлы күрсәтмәсе (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 7 октябрендәге 2580-р номерлы күрсәтмәсе белән кертелгән үзгәрешләр белән);

Россия Мәгариф министрлыгының «Педагогик хезмәткәрләргә һәм идарәче кадрларга фәнни-методик ярдәм күрсәтүнең бердәм федераль системасын төзү концепциясен раслау турында» 2020 елның 16 декабрендәге Р-174 номерлы күрсәтмәсе;

Россия Мәгариф министрлыгының «Педагогик хезмәткәрләргә һәм идарәче кадрларга фәнни-методик ярдәм күрсәтүнең бердәм федераль системасын булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2021 елның 4 февралендәге күрсәтмәсе;

Россия Мәгариф министрлыгының «Индивидуаль план алу мөмкинлеге белән мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәрләренең һәм идарәче кадрларының һөнәри дефицитларын диагностикалау тәртибе һәм формалары буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2021 елның 27 августындагы Р-201 номерлы күрсәтмәсе;

Педагогик хезмәткәрләргә һәм идарәче кадрларга фәнни-методик ярдәм күрсәтүнең региональ системасын булдыру һәм гамәлгә кертү буенча Россия Федерациясе субъектлары өчен, «Россия Мәгариф министрлыгы академиясе» өстәмә һөнәри белем бирү федераль дәүләт мәгариф учреждениесенең 2021 елның 6 июнендәге 2163 номерлы хаты белән җибәрелгән өстәмәләр белән, методик тәкъдимнәр

федераль дәүләт белем бирү стандартлары.

4.2. Татарстан Республикасы Россия Федерациясе мәгариф системасын үстерүнең өстенлекле юнәлешләре; белем бирү эшчәнлеген регламентлаштыра торган башка норматив хокукый актлар; бала хокуклары турында конвенция.

4.3. Дидактика принциплары; педагогика һәм яшь психологиясе нигезләре; укытуның гомуми һәм хосусый технологияләре; укыту предметын яисә эшчәнлек юнәлешен методик тәэмин итү принциплары; белем бирү учреждениесендә белем бирү процессын оештыру системасы; укыту-программа документациясен, белем бирү программаларын, уку җиһазларының типлаштырылган исемлекләрен һәм башка укыту-методик документацияне эшләү принциплары һәм тәртибе.

4.4. Педагогик эшнең нәтиҗәле формаларын һәм методларын ачыклау, гомумиләштерү һәм тарату методикасы; мәгариф учреждениеләре педагогик хезмәткәрләренең методик берләшмәләрен оештыру принциплары һәм эш эчтәлеге; нәшриятлар белән эшләү нигезләре; методик һәм мәгълүмати материалларны системалаштыру принциплары; интерактив укыту чараларына төп таләпләр; белем бирү системалары белән идарә итү теориясе һәм методлары.

4.5. Продуктив, дифференциацияле, үстерелешле укытуның, компетентлылы якын килүне гамәлгә ашыруның заманча педагогик технологияләре; ышандыру, үз позицияңне аргументацияләү, педагогик хезмәткәрләр белән элемтә урнаштыру ысуллары; конфликтлы ситуацияләрнең сәбәпләрен диагностикалау, аларны профилактикалау һәм хәл итү технологияләре; экология, икътисад, социология нигезләре.

4.6. Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре; хезмәтне саклау һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре; муниципаль район (шәһәр округы) мәгариф идарәсенең (бүлегенең) уставы; вазыйфаи инструкция һәм башка локаль норматив актлар.

## V. Методист хокуклары (өлкәнне дә кертеп)

5.1. Методист хокуклы:

бүлекнең мәгълүмати һәм методик фондларыннан, укыту, методик һәм башка бүлекчәләре хезмәтләреннән, кирәкле җайланмалардан файдаланырга;

бүлекнең методик, укыту-методика эшен камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

педагогик хезмәткәрләрнең, педагогик коллективларның авторлык методикаларын, мәгариф һәм фән өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органнарының закон нормаларын һәм методик тәкъдимнәрен куллануның уңай тәҗрибәсен исәпкә алып, педагогик хезмәткәрләр өчен укыту методларын һәм чараларын эшләргә.

## VI. Методистның (өлкәнне дә кертеп) җаваплылыгы

6.1. Методист түбәндәгеләр өчен җаваплы:

вазыйфаларны, шулай ук «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы йөкләмәләрен башкаруның сыйфаты һәм үз вакытында башкарылуы;

«Мәгариф идарәсе» МКУ компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча югарырак органнарның указларын, карарларын һәм күрсәтмәләрен үтәү;

хисап мәгълүматларының, белешмәләрнең һәм башка материалларның үз вакытында булуы һәм дөреслеге;

хезмәтне саклауның янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу.

6.2. Үз вазыйфаи бурычларын, актлар таләпләрен һәм әлеге вазыйфаи инструкциядә санап үтелгән күрсәтмәләрне һәм закон таләпләрен нигезле сәбәпләрсез үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен, методист закон нигезендә җаваплылыкка ия.

## VII. Методист (өлкәнне дә кертеп) эшчәнлегенең эффективлык һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре

7.1. Методист эшчәнлеген белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә

ашыручы җитәкчеләр һәм методистлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләүнең муниципаль берәмлек тарафыннан расланган критерийлары нигезендә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 10.08.2015 № под-8749/15 боерыгын исәпкә алып башкарырга тиеш.

7.2. Методист эшчәнлегенең нәтиҗәлелек күрсәткечләре ел саен «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан эшләнә.

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең мәгълүмат-методика бүлеге методисты (өлкәнне дә кертеп) компетенцияләре паспортына кушымта

## Методист (өлкәнне дә кертеп) эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүнең типлаштырылган критерийлары

| № | Критерий | Күрсәткечләр | Максималь баллар саны | Нәтиҗәләрне раслау |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Методистның һөнәри эшчәнлеге нигезләре | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә һөнәри бурычларны үтәгәндә үз-үзеңне тотуның этик нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү. | 1 балл | Администрациягә һәм мәгариф белән идарә итүнең югарырак органнарына шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр булмау, структур бүлекчәләр һәм администрация җитәкчеләренең мәгълүматы |
| | | Бердәм методист документациясен алып бару системасы турында нигезләмә нигезендә документацияне сыйфатлы һәм үз вакытында рәсмиләштерү (булуы). | 1 балл | Методик эшне алып баручы, укыту-тәрбия эше буенча директор урынбасарының контроль нәтиҗәләре |
| | | Муниципаль максат һәм бурычлар булу:<br>1. идарә эшчәнлегенең сыйфатын арттыру буенча<br>2. мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һөнәри компетенцияләрен формалаштыру буенча<br>3. укучыларны әзерләү сыйфатын тәэмин итү буенча<br>4. идарәче кадрлар резервын формалаштыру буенча | <br>1 балл<br>1 балл<br>1 балл<br>1 балл | документлар: муниципаль программа, концепция, нигезләмә, модель, методология һ. б. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2. | Методистның инновацион эшчәнлеге | Белем бирү һәм тәрбия программаларын, инновация проектларын, аларны гамәлгә ашыру буенча юл карталарын эшләү (экспертиза). | 3 балл | Программаларны раслау (программаларны конкурска җибәрү) турында боерык экспертиза материаллары (рецензияләр, эксперт бәяләмәләре) булу |
| | | Эштә мәгълүмат технологияләрен һәм Интернет-ресурсларны һәм социаль челтәрләрне гамәлгә кертү һәм актив куллану. | 2 балл | Документаль теркәлгән нәтиҗәләр, Интернет-ресурсларга сылтамалар һ. б. |
| | | Проект эшчәнлегендә катнашу. | 1 балл – муниципаль дәрәҗәдә;<br>2 балл – төбәк дәрәҗәсендә | Документаль теркәлгән нәтиҗәләр |
| 3. | Методистның һөнәри һәм иҗтимагый активлыгы | Иҗтимагый советлар, иҗади төркемнәр, эксперт комиссияләре эшенә җитәкчелек итү. | 2 балл | Тиешле дәрәҗәдәге боерык |
| | | Эксперт һәм эшче төркемнәр, комиссияләр, жюри составында эшчәнлек; конкурслар, олимпиадалар оештыру. | 1 балл – муниципаль дәрәҗәдә;<br>2 балл – төбәк дәрәҗәсендә | Боерыклар, беркетмәләр, грамоталар, дипломнар |
| | | Педагогик хезмәткәрләр эшенең гамәли нәтиҗәләрен гомумиләштерү, гамәлгә кертү һәм трансляцияләү, тәҗрибәне массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту. | 1 балл – муниципаль дәрәҗәдә;<br>2 балл – төбәк дәрәҗәсендә | Тиешле дәрәҗәдәге боерык, ММЧ материаллары |
| | | Педагогик басмаларда һөнәри эшчәнлек буенча методистның шәхси публикацияләре булу. | 1 балл – муниципаль дәрәҗәдә;<br>2 балл – төбәк дәрәҗәсендә | Басма |
| | | Төрле дәрәҗәдәге методик чараларны оештыру, үткәрү, актив катнашу (семинарлар, мастер-класслар, стажировка мәйданчыклары, форумнар, педагогик укулар). | 1 балл – муниципаль дәрәҗәдә;<br>2 балл – төбәк дәрәҗәсендә; | Раслаучы документлар (боерык, программа, белешмә) |
| | | Учреждениенең социаль җәлеп итүчән имиджын булдыру һәм аңа ярдәм итү эшендә актив катнашу, учреждение сайтына ярдәм итү. | 2 балл | Мәгълүмат булу һәм аңлаешлы булу, учреждениене төрле дәрәҗәләрдә күрсәтү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Мәгариф учреждениеләренең социаль партнерлар белән үзара хезмәттәшлеген оештыру. | 1 балл – бер тапкыр үткәрелә торган чаралар;<br>2 балл – уку елы дәвамында системалы хезмәттәшлек. | Раслаучы документлар (боерык, программа, белешмә) |
| | | Эштә компьютер техникасын куллану, компьютер программалары белән эшли белү. | 2 балл | Кисәтүләр, күрсәтмәләр булмау |
| | | Эш нәтиҗәләрен анализлауны исәпкә алып эшләнгән уңышлы практикалардан файдалану буенча тәкъдимнәр булу. | 1 балл | Документаль |
| | | Үткәрелгән чараларның, кабул ителгән чараларның һәм идарә карарларының нәтиҗәлелегенә анализ ясау. | 1 балл | Документта чаралар үткәрү нәтиҗәләре булырга тиеш, кабул ителгән чараларның нәтиҗәлелеген анализлау нәтиҗәсе булып проблеманы билгеләү тора |
| 4. | Һөнәри эшчәнлектә шәхси нәтиҗәләр | Һөнәри конкурсларда методистның шәхсән катнашуы. | 1 балл – төбәк;<br>2 балл – Бөтенроссия; | Грамоталар, дипломнар, боерыклар, сертификатлар |
| | | Һөнәри казанышлар өчен бүләкләүләр булу һәм һөнәри эшчәнлекне җәмәгатьчелек тарафыннан тану. | 1 балл – муниципаль дәрәҗәдә;<br>2 балл – төбәк дәрәҗәсендә; | Грамоталар, рәхмәт хатлары, боерыклар, таныклыклар, дипломнар, бәяләмәләр |
| 5. | Кураторлык юнәлешләре буенча нәтиҗәләр | Методист тарафыннан кураторлык юнәлеше буенча квалификация категориясе булган педагогик хезмәткәрләр өлеше | 1 балл – 50%ка кадәр<br>2 балл – 50%тан артык | Раслаучы приказлар. |
| | | Һөнәри дефицитларны диагностикалау һәм бетерү мәсьәләләре буенча педагогик хезмәткәрләргә методик ярдәм күрсәтүне оештыру. | 1 балл – бер тапкыр үткәрелә торган чаралар;<br>3 балл – уку елы дәвамында критерийны гамәлгә ашыруның системалылыгы, ЦОК һәм ЦНППМ+ өстәмә һөнәри белем бирү белән үзара хезмәттәшлек | Раслаучы документлар (боерык, программа, белешмә) |
| | | Мәгариф учреждениеләре педагогик | 1 балл – бер тапкыр үткәрелә | Боерыклар, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | хезмәткәрләренең һөнәри үсеше өчен шартлар тудыру. | торган чаралар;<br>2 балл – критерийны гамәлгә ашыруның системалылыгы | программалар, сертификатлар, грамоталар, дипломнар. |
| | | Юнәлеш буенча педагогик хезмәткәрләрнең проект эшчәнлегендә катнашуы. | 1 балл – муниципаль дәрәҗәдә;<br>2 балл – төбәк дәрәҗәсендә | Документаль теркәлгән йомгаклар |
| | | Һөнәри конкурсларда (мәгариф һәм тәрбия программалары, методик материаллар конкурсларында) призер педагоглар әзерләү. | 1 балл – муниципаль дәрәҗәдә;<br>2 балл – төбәк һәм бөтенроссия дәрәҗәсендә | Конкурсларның документаль теркәлгән нәтиҗәләре (боерыклар, грамоталар) |
| | | Бөтенроссия укучылар олимпиадасының республика этапларында, төбәк һәм йомгаклау этапларында призерлар, җиңүчеләр булу. | 1 балл – республика олимпиадасы һәм Бөтенроссия укучылар олимпиадасының төбәк этабы призеры;<br>2 балл – республика олимпиадасы һәм Бөтенроссия укучылар олимпиадасының төбәк этабы җиңүчесе;<br>3 балл – Бөтенроссия укучылар олимпиадасының йомгаклау этабы призеры | Конкурсларның документаль теркәлгән нәтиҗәләре (боерыклар, грамоталар) |
| | | Укучылар өчен республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә җиңүчеләр һәм призерлар булу. | 1 балл – республика дәрәҗәсендәге призер;<br>2 балл – республика дәрәҗәсендә җиңүче;<br>3 балл - бөтенроссия дәрәҗәсендәге призер һәм җиңүче | Конкурсларның документаль теркәлгән нәтиҗәләре (боерыклар, грамоталар) |
| | | Интернет челтәрендә белем бирү процессында катнашучыларның челтәрдәге үзара хезмәттәшлеген координацияләү. | 1 балл – «Татарстан Республикасында электрон белем бирү» мәгълүмат системасында<br>2 балл – федераль һәм төбәкара дәрәҗәдәге мәгариф берләшмәләрендә | Методист җитәкләгән челтәр берләшмәләре булу. |
| | | Тематик өйрәнүләр үткәрү, дәресләргә һәм | 1 балл – гомуми характердагы | Раслаучы документлар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | чараларга йөрү. | нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр булу;<br>2 балл – конкрет нәтиҗәләр һәм адреслы киңәшләр булу | (боерык, белешмә) |
| | | Укучыларның функциональ грамоталылыгын булдыру һәм үстерү буенча педагогик хезмәткәрләр эшчәнлеген координацияләү һәм аларга методик ярдәм күрсәтү | 1 балл - бер тапкыр үткәрелә торган чаралар;<br>2 балл – критерийны гамәлгә ашыруның системалылыгы | Раслаучы документлар (боерык, программа, белешмә) |
| | | Укучыларның функциональ грамоталылыгын булдыру буенча укыту-методик һәм контроль-үлчәү материалларының муниципаль банкын формалаштыру | 2 балл – булу | Электрон басмаларга, басма материалларга сылтамалар. |
| Барлык баллар | | | 60 | |